ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮГӘ, АЛАРНЫҢ ӘЙЛӘНЕШЕНӘ ҺӘМ СЫЙФАТЫНА ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУНЫ ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ФӘН ҺӘМ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ

БОЕРЫК

Казан ш.

19.06.2021ел. №10-07/114 / под-898/21

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасын үткәрү турында

«2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.10.2013 764 номерлы карары нигезендә, БОЕРЫК БИРӘБЕЗ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасын оештыру һәм үткәрү турында тәкъдим ителгән нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә).

2. 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасын расланган Нигезләмәгә туры китереп оештырырга һәм үткәрергә (алга таба – Олимпиада).

3. Татарстан Республикасының фән һәм мәгариф Министрлыгына (М.З. Закирова) әлеге боерыкны муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә (Ф.Г. Хамматов) – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге начальнигына, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары җитәкчеләренә, Олимпиаданың оештыру комитеты әгъзаларына җиткерергә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Ф.Г. Хамматовка һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары М.З. Закировага йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча Дәүләт инспекциясе җитәкчесе | Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры |
| __________________ Ж.Й.Әхмәтханов | _____________________ И.Г.Һадиуллин |

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгының уртак боерыгы белән
РАСЛАНГАН
29.06.2021ел.
№ 10-07/114 / под-898/21

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республикакүләм олимпиаданы оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге нигезләмә 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасының максатларын һәм бурычларын (алга таба – Олимпиада), аны үткәрү тәртибен, оештыру-методик тәэмин ителешен, катнашу шартларын, катнашу өчен гариза формаларын, шулай ук җиңүчеләрне һәм призерларны билгеләү тәртибен, аларны бүләкләү процедурасын билгели.

1.2. Олимпиада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклауның комплексы системасын үстерү» ярдәмче программасы (алга таба - Программа) кушымтасының 2.1 пункты нигезендә үткәрелә.

1.3. Олимпиаданы оештыручылар – Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча Дәүләт инспекциясе (алга таба - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе), Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгы.

## II. ОЛИМПИАДАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Олимпиаданың максатлары:

кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә белемнәрне популярлаштыру, гомуми белем бирү оешмалары укучыларының товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне куллану базары мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнүгә мотивациясен

арттыру, норматив-хокукый актларны һәм аларны куллана белү, шулай ук бу өлкәдә укучыларның иҗади потенциалын ачуда ярдәм итү, кулланучылар буларак үз хокукларын яклау белән кызыксынуларын арттыру һәм актив гражданлык позициясен булдыру.

2.2. Олимпиада бурычлары:

укучыларның кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнүгә кызыксынуларын арттыру;

укучыларда товарларның, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең куллану базары турындагы белемнәрен, кулланучы буларак үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләрен формалаштыру, кулланучы буларак үз хокукларын мөстәкыйль яклый белүне формалаштыру;

гомуми белем бирү оешмалары укучыларында фәнни эшчәнлеккә кызыксыну уяту һәм иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү, сәләтле балаларга ярдәм итү өчен кирәкле шартлар тудыру, фәнни белемнәрне пропагандалау.

## III. ОЛИМПИАДАНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Олимпиада үткәрү турында мәгълүмат 2021 елның 25 августына кадәр кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Порталына урнаштырыла (https://www.tatzpp.ru) (алга таба – кулланучылар хокукларын яклау буенча Портал)

3.2. Олимпиадада, ирекле рәвештә, гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче, кулланучылар хокукларын яклау буенча Порталда электрон формада гариза тутырган 8-11 сыйныф укучылары катнаша ала (Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта).

Олимпиадада катнашучы, Олимпиадада катнашу теләге турында белдереп, гаризада күрсәтелгән мәгълүматның дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы. Үзләре турында тулы булмаган һәм төгәл булмаган мәгълүмат биргән Олимпиада катнашучылары, шул исәптән, белем алу сыйныфын дөрес күрсәтмәгәннәр дә, катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла. Олимпиадада катнашу өчен гаризаны теркәүнең тулы кагыйдәләре һәм шартлары әлеге Нигезләмәнең 2 кушымтасында чагылдырылган.

3.3. Теркәү 2021 елның 2 сентябреннән 15 сентябренә кадәр чорда үткәрелә. Олимпиадада катнашучыларның исемлеге 2021 елның 20 сентябрендә кулланучылар хокукларын яклау Порталында урнаштырыла.

3.4. Олимпиаданы үткәрү вакыты:

ике этпта үткәрү очрагында 2021 елның 22 сентябреннән 26 октябренә кадәр;

өч этапта үткәрү очрагында 2021 елның 22 сентябреннән 22 ноябренә кадәр

3.5. Олимпиада өч этаптан тора:

I этап - башлангыч (сайлап алу) – 2021 елның 22 сентябреннән 26 сентябренә кадәр үткәрелә. Теркәлгән катнашучылар I этапны дистанцион формада тест биремен үтәү рәвешендә уза.

Тест биремнәрендә 15 сорау (төрле авырлыктагы 5әр сорау (җиңел, уртача, катлаулы) һәм алар 2021 елның 22 сентябрендә кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

Олимпиаданың I этабы нәтиҗәләре турында мәгълүмат 2021 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

II этап - 2021 елның 5 октябреннән 12 октябренә кадәр, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә бирелгән тематикага эссе рәвешендә иҗади биремне үтәү буларак дистанцион формада үткәрелә.

Эссе темалары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан 2021 елның 5 октябрендә кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

Олимпиадада катнашучыга «Кулланучылар хокукларын яклау» темасына кагылышлы конкрет проблема буенча иҗади инша әзерләргә, аның мәгънәсен ачарга, төрле аспектларны билгеләргә, үз карашын формалаштырырга һәм нигезләргә кирәк. Фикерләрне бәян иткәндә, тиешле төшенчәләрдән файдаланып, үз фикереңне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларын дәлилләргә кирәк.

Эссе тексты аның атамасыннан ике-өч юл интервалы белән бүленә. Эссе doc яки docx форматында рус яки татар телләрендә 3 биттән дә артмаган күләмдә кабул ителә. Форматы - А4. Кырлар: сул як - 2 см, уң як -1,5 см, югары - 2 см, түбән - 2 см., сүз күчерүләр рөхсәт ителә. Битләр, һичшиксез номерланган булырга тиеш. Бит номерлары документның югары кыр уртасында булырга тиеш. Шрифт: Times New Roman, кегль - 14. Юлара интервал – бер ярым. Текстны тигезләү - киңлеге буенча.

Конкурсантларның эшләре электрон почта адресына җибәрелә: Zpp.Olimpiada@tatar.ru

Олимпиаданың әлеге этабы нәтиҗәләре турында мәгълүмат 2021 елның 26 октябренә кадәр кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

III этап – йомгаклау этабы, 2021 елның 1 ноябреннән 8 ноябренә кадәр үткәрелә. III этапны үткәрү урыннары һәм көннәре 2021 елның 27 октябрендә кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

Татарстан Республикасында яңа короновирус инфекциясе таралу белән бәйле санитар-эпидемиолог халәтне искә алып, III этапны үткәрү яки үткәрмәү турындагы мәгълүмат кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә 2021 елның 27 октябрендә урнаштырыла.

III этап 2 турдан тора.

1 тур – язма рәвештә тест узу, 2 тур – билетлар буенча сорау-җавап форматында, конкурсантлар белән әңгәмә рәвешендә уздырыла.

Олимпиадада катнашучылар әңгәмәне, үз теләкләре буенча, рус телендә дә, татар телендә дә үтә ала.

Олимпиада нәтиҗәләре катнашучылар өчен 2021 елның 22 ноябрендә ясала.

Олимпиаданың III этабы оештырылмаган очракта, II этап нәтиҗәләре исәпләнәчәк.

3.6. Олимпиада биремнәрен бәяләү критерийлары:

3.6.1. I этапның тест биремнәре һәр дөрес җавап өчен сорауларның катлаулылыгына бәйле рәвештә бәяләнә:

«җиңел» категориядәге сорауга 1 балл;

«уртача» категориядәге сорауга 2 балл;

«катлаулы» категориядәге сорауга 3 балл.

I этап өчен максималь бәя - 30 балл.

3.6.2. Эссе 3 критерий буенча бәяләнә:

эссе темасының ачылышы, эш эчтәлегендә проблеманы аңлау дәрәҗәсе (1-10 балл);

фикерләрдә һәм аргументларда теоретик нигезләмәләрне, нәтиҗәләрне һәм факттагы материалларны куллану (1-10 балл);

катнашучының иҗади эше эчтәлегендә үз позициясен чагылдыра белү (1-10 балл).

Олимпиаданың II этабы өчен максималь бәя - 30 балл.

3.6.3. Йомгаклау III этап биремнәре түбәндәгечә бәяләнә:

1 турның тест сорауларына дөрес җавап өчен жюри 1 балл куя (тестта барлыгы 25 сорау). Тестны үтү өчен катнашучыга 25 минут вакыт бирелә;

2 тур җаваплары өчен (билетта бер сорау) жюри җавапларның тулы һәм төгәллегенә карап 1 баллдан 10 баллга кадәр бәя куя (сорауга җавапны ачканда дөрес, аргументланган, норматив хокукый актларга таянып, тормыштан китерелгән мисаллар белән). Билет сайлап алу Олимпиадада катнашучы тарафыннан башкарыла, билетлардагы сораулар күренми торган ягы белән җәелә. Сорауга җавап әзерләр өчен 5 минут вакыт бирелә.

Олимпиаданың III этабының 1 турында максималь бәя – 25 балл.

Олимпиаданың III этабының 2 турында максималь бәя – 10 балл.

3.7. Олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары 8-9 сыйныф укучылары һәм 10-11 сыйныф укучылары арасында билгеләнә (ике яшь төркеме буенча). Иң күп балл җыйган катнашучылар Олимпиада җиңүчеләре дип танылa.

3.8. Олимпиада нәтиҗәләре турында мәгълүмат 2021 елның 26 октябреннән дә соңга калмыйча (ике этапта үткәргән очракта) һәм 2021 елның 22 ноябреннән дә соңга калмыйча (өч этапта үткәргән очракта) кулланучылар хокукларын яклау Порталында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

3.9. Олимпиадада катнашучы Олимпиада нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, оештыру комитетына Zpp.Olimpiada@tatar.ru. электрон адресына апелляция бирергә хокуклы.

Апелляция язма рәвештә, кулланучылар хокукларын яклау Порталында Олимпиада нәтиҗәләре басылганнан соң, өч эш көне дәвамында бирелә.

Оештыру комитеты, апелляция кергән көнне аны жюри әгъзаларына бирә.

Апелляция, жюри әгъзаларының өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган составта, жюри утырышында, кергән көннән соң дүрт эш көне дәвамында карала.

Жюри түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне кире кагу һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Карар кабул итү күпчелек тавыш бирү юлы белән башкарыла.

Тавышлар саны тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Жюри утырышы узганнан соң 3 көн вакыт эченедә кабул ителгән карар протокол рәвешендә басылып чыга.

Протоколны барлык жюри әгъзалары да имзалый.

Оештыру комитеты, протоколга кул куелганнан соң өч календарь көн эчендә Олимпиадада катнашучыга аның апелляциясе буенча кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында карар кабул ителгән очракта, жюри карары имза куелган көнне үк кулланучылар хокукын яклау Порталында урнаштырылырга тиеш.

Жюри карары апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча ахыргы карар булып тора, яңадан каралырга тиеш түгел һәм суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## IV. ОЛИМПИАДАНЫҢ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ ҺӘМ ЖЮРИ

4.1. Олимпиада белән гомуми җитәкчелек итү оештыру комитеты тарафыннан башкарыла. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгы, кулланучылар хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр, мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары укытучылары вәкилләреннән төзелә.

4.2. Олимпиаданы оештыру комитеты:

Олимпиада үткәрү регламентын билгели;

Олимпиаданы үткәрүне турыдан-туры тәэмин итә;

Олимпиаданың жюри составын формалаштыра;

Олимпиада нәтиҗәләрен анализлый, гомумиләштерә һәм раслый;

Олимпиадада катнашучыларның апелляцияләрен жюри әгъзаларына җибәрә;
Олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары исемлеген раслый;
Олимпиаданың жюри карарын беркетмә белән рәсмиләштерә;
Олимпиада җиңүчеләрен һәм призерларын бүләкли.
Олимпиаданың оештыру комитетына олимпиаданы үткәрүне оештыруны камилләштерү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне кертә.

4.3. Олимпиадада катнашучыларның эш нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү максатларында жюри составы булдырыла. Оештыру комитетының җиде вәкиленнән торган жюри составы Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

Олимпиаданың жюри составы:

Олимпиадада катнашучыларның Олимпиада биремнәрен һәм башка төр сынауларны үтәү нәтиҗәләрен тикшерә һәм бәяли;

Олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары кандидатураларын билгели;

Олимпиадада катнашучыларның апелляцияләрен карый һәм аларны тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итә.

4.4. Жюри эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда, вазыйфалар аның урынбасарына йөкләнә.

Жюри әгъзалары булып Олимпиада нәтиҗәләре белән кызыксынган затлар катнаша алмый.

4.5. Жюри эше утырышта алып барыла. Утырыш, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Жюриның җаваплы сәркатибе тавыш бирергә хокуклы түгел.

Җаваплы сәркатип жюри утырышын оештыра, документлар әзерли һәм беркетмә төзи.

4.6. Жюри карары утырышта катнашучы әгъзаларының балл суммалары нигезендә кабул ителә һәм беркетмә төзелә, ул утырышта катнашучы жюри әгъзалары, рәис һәм җаваплы сәркатип тарафыннан имзалана. Тигез баллар саны булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Протоколны рәсмиләштерү срогы жюри утырышы уздырылганнан соң 5 эш көне тәшкил итә.

## V. КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ

5.1. Олимпиадада җиңүчеләр дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

5.2. Олимпиада призерлары (1, 2, 3 дәрәҗә призерлар) дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

5.3. II этапка узган Олимпиадада катнашучыларга «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча электрон формада Олимпиадада катнашучы Сертификатлары бирелә.

5.4. Кулланучылар хокукларын яклау буенча республика Олимпиадасында аеруча актив катнашкан һәм укучыларны кулланучылар белемнәре өлкәсендә югары дәрәҗәдә әзерләгән Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары педагоглары оештыру комитетының Рәхмәт хатлары һәм кызыксындыру бүләкләре белән бүләкләнәләр.

5.5. Татарстан Республикасында кулланучылар мәгарифе системасын үстерүгә зур өлеш керткән гомуми белем бирү оешмасы диплом һәм бүләк белән бүләкләнә.

5.6. Җиңүчеләрне бүләкләү Олимпиадага йомгак ясаганнан соң башкарыла.

## VI. ФИНАНСЛАУ

Олимпиаданы финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.10.2013 елның 764 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республикакүләм олимпиадасын үткәрү турында Нигезләмәгә 1 кушымта

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында
«Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча олимпиадада катнашу өчен гариза

Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында үткәрелүче «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча олимпиадада катнашырга теләк белдерәм.

Мәҗбүри мәгълүмат тапшыру кырлары

1. Олимпиадада катнашучының исем-фамилиясе, атасының исеме (тулысынча):

_____________________________________________________________________

2. Катнашучыны әзерләгән укытучының, предметын күрсәтеп: исем-фамилиясе, атасының исеме (тулысынча):

_____________________________________________________________________

3. Олимпиадада катнашучының контакт телефоны:________________________________

4. Олимпиадада катнашучының электрон почта адресы (E-mail):

______________________________________________________________________

5. Гомуми белем бирү оешмасының исеме (исеме һәм белем бирү оешмасының номеры)):____________________________________________________________

6. Гомуми белем бирү оешмасының адресы:

______________________________________________________________________

7. Сыйныф: __________

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучылар хокукларын яклау» темасы буенча республикакүләм олимпиадасын үткәрү турында Нигезләмәгә 2 кушымта

## Укучылар өчен мәгълүмат

Олимпиадада гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче 8-11 сыйныф укучылары ирекле рәвештә катнаша ала.

Олимпиадада катнашучы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы. Оештыру комитеты, техник проблемалар сәбәпле дөрес булмаган гаризалар теркәлгәндә, дәгъвалар кабул итми һәм аларны карамый. Дөрес булмаган мәгълүматлар бирелгән очракта, гариза биргән катнашучы белән элемтәгә чыгу мөмкин булмаганда, оештыру комитеты җаваплылыкны үз өстенә алмый.

Уку сыйныфын дөрес күрсәтмәгән Олимпиадада катнашучылар Олимпиадада катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла.

Теркәлү вакытында һәр катнашучы үзенең электрон почта адресын күрсәтергә тиеш. Бер электрон почта адресы буенча ике һәм аннан да күбрәк катнашучыны теркәү мөмкин түгел.

Һәр катнашучы бер генә тапкыр теркәлергә мөмкин. Кабат теркәлү мөмкин түгел.

Мәҗбүри теркәү кырларын рус телендә, хаталарсыз тутырырга, дөрес язу кагыйдәләрен үтәргә.

Барлык теркәү мәгълүматлары кертелгәннән соң, Сез күрсәтелгән электрон почта адресы буенча хат алачаксыз һәм хаттагы сылтама аша узып, теркәлүегезне раслыйсыз. Әгәр хат озак вакыт килми торса, игътибар белән үзегезнең почта ящигын тикшерегез.

Теркәлгән, ләкин раслау турында хат алмаган очракта, үзегезнең исем-фамилиягез, атагызның исемен һәм электрон почта адресыгызны күрсәтеп, оештыру комитетына электрон хәбәр языгыз, бу очракта Сезнең теркәлүне үзебез раслыйбыз.

Олимпиаданы оештыру комитеты:

Телефон: (843) 277-94-99, 277-94-95 (дүшәмбедән җомгага кадәр: 09.00 дән 17.00 гә кадәр)

Кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Порталы: https://www.tatzpp.ru/

Электрон почта: Zpp.Olimpiada@tatar.ru